БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 июль 2019 ел № 202

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Балтач муниципаль районы милкендә булган һәм өченче затлар хокукларыннан (кече эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт исемлегенә өстәмәләр кертү турында**

Балтач муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатыннан «Россия Федерациясе җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елнын 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (кече эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт исемлеген формалаштыру тәртибе, алып бару һәм бастырып чыгару турында»гы 2016 елның 11 ноябрендәге 61 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2017 елның 20 декабрендәге 107 номерлы карары белән расланган (01.11.2018 үзгәрешләр белән) Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Балтач муниципаль районы милкендә булган һәм өченче затлар хокукларыннан (кече эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт исемлеген 1 нче номерлы кушымтада каралганча тулыландырырга.
2. Балтач муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасына әлеге карарның 1 нче номерлы кушымтасын «Хезмәт» район газетасында бастырырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин

№ 202 25.07.2019 елгы
Татарстан Республикасы
Балтач район Советы карарына
1 нче номерлы кушымта

**Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Балтач муниципаль районы милкендә булган һәм өченче затлар хокукларыннан (кече эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) ирекле мөлкәт исемлегенә өстәмәләр**

| **№** | **Мөлкәтнең исеме** | **Мөлкәт урнашу урыны** | **Мәйдан (кв.м.)** |
|---|---|---|---|
| 7. | Торак булмаган бина | РТ, Балтач муниципаль районы, Балтач шәһәр тибындагы поселок, Нариман урамы, 21А йорт, бүлмә 1000 | 71,1 |